


# СЦЕНАРИЙ

театрализованного пролога
Казанского Сабантуя 2024 года

# «АЗАМАТ КЫЙССАСЫ»
# («СКАЗАНИЕ ОБ АЗАМАТЕ»)

*(на основе татарской народной сказки «Три вопроса»*
*и предания «Праздник Наджар»)*

**21.06.2024**

**Сценарий авторы – Р.Ф.Мөхәммәтшин, Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты**

## *Главные герои:*

**Азамат** – молодой человек (20 лет), три года назад отправившийся вместе с купцами в Великий город (Биляр) для учебы в университете (дар аль-гулюм) и успевший до возвращения в родные края посетить диковинные страны (аллюзия на страны БРИКС).

**Аман – би** (предводитель) племени (40 – 45 лет), в нашем контексте: голова селения (катау ) Кызылъяр.

**Наджар** – невеста, дочь Амана (18 лет). ГЗК (голос за кадром) принадлежит ей.

**Тимербулат** – сын Амана (20 лет).

**Кам** – духовное лицо, священник (в язычестве).

## *Эпизодические персонажи:*

**Отец Амана** (65 – 70 лет).

**Мать Амана** (60 – 65 лет).

**Супруга Амана** (38 – 40 лет).

**Население (массовка):**

аксакалы-старцы, мужчины, женщины, молодые девушки, юноши, дети.

*Действие происходит в начале XI века в условном селении (катау) Кызылъяр Волжской Булгарии,огороженном частоколом. В центре – ворота.*
*По бокам – сторожевые башни.*

## 1 картина (≈ 2 мин.)

*Открываются ворота. Выходят Кам и старцы. Среди них есть и Аман. Они из разных мест поля берут по клочку земли,растирают его на ладонях,прижимают к губам.*

**Кам.** Җир-Анабыз өлгердеме икән, ырудашлар? Йола кушканча, йомырка тәгәрәтеп карыйк. Йомырка еракка китсә, туфрак өлгергән, димәк. Бер-ике тәгәрәүгә туктап калса, иртәрәк булыр әле. Алай булса, ашыкмабыз. Ашыккан эштә хәер юк.

*Старцы становятся в круг и по партиям начинают катать по полю крашеные (желательно красные – вареные в луковой шелухе) яйца. В это время Кам начинает читать алгыш-восхваление в сопровождении тюркских музыкальных инструментов: кылкубыз,барабан, кубыз и пр. К его алгышу поэтапно присоединяется все население.*

Күк, Җир!
Күк, Җир!
Дәвер белән дәүләт бир,
Имин гомер теләп бир,
Җиргә Күк игез булсын,
Утка Су игез булсын,
Килер ел симез булсын,
Һәр тараф тигез булсын!
Куәтен бир, көчен бир,
Имин тормыш өчен бир!
Күк, Җир!
Күк, Җир!

**Кам** (*убеждается*). Өлгергән! Тәмам өлгергән!

*Дети собирают яйца, раскиданные по полю.*

**ГЗК (Наджар).** Безнең илдә Сабан туе – иң изге, иң гүзәл бәйрәм. Ул, чын мәгънәсендә, гомум гаилә, гомум халык бәйрәме. Бала-чага аны күңелле уеннары, шикәр, сагыз кебек тәм-томнары өчен көтеп ала. Өлкәннәр өчен Сабан туе – табигатькә сыену, көч сынашу вакыты, яз һәм хезмәт бәйрәме!

**Кам.** Җир-Анабыз әзер! Башладык!

## 2 картина (≈ 3 мин.)

*В этот момент со всех сторон майдана выходят мужчины с запряженными лошадьми,быками,и распахивают поле. После завершения работ в центре оказываются Кам и Аман.*

*Кам вручает Аману лукошко с зерном.*

**Кам.** Башлыгы уңмаганның ашлыгы уңмас. Син, Аман, ыруыбыз башлыгы, күңелеңнән изге теләгеңне әйтеп, эш башла!

*Аман надевает лукошко,бросает на землю зерна. После пары фраз и движений к нему присоединяются другие.*

**Аман** *(сеет)*.
Бөртек янына бөртек бир,
Учма янына учма бир,
Учма янына көлтә бир,
Көлтә янына чүмәлә бир,
Чүмәлә янына кибән бир,
Кибәннәрне сугып, икмәк ашарга язсын!

## 3 картина (≈ 2 мин.)

**ГЗК.** Ә сез яшь егет-кызларның бу бәйрәмне ни өчен көтеп алуын беләсезме? Чөнки Сабан туе – көзге мул уңыш, ә мул уңыш – шаулап-гөрләп узган туйлар, өйләнешү, ныклы гаилә кору, дигән сүз. Дөрес, мин быел Сабан туен көтмим. Хәлемнән килсә, аны бөтенләй булдырмас идем.

Минем исемем Нажар. Мин – Кызылъяр башлыгы Аманның кызы.

Сабан аенын җылы көне кичкә авышты. Чәчү эшләре төгәлләнеп килә иде. Шулвакыт катау капкаларында ул – билгесез егет пәйда булды.

*Азамат на коне прибывает в селение. Он в черном иноземном (арабском?) одеянии. На черном коне. Не доезжая до Амана,спешивается. Дальше идет пешком.*

**Азамат.** Саумысыз, мөхтәрәм ага! Эшегез уң булсын, уңышыгыз мул булсын!

**Аман.** Рәхмәт, юлчы. Яхшы сүз – җан азыгы. Үзең нихәл? Изге ният белән йөрисеңме?

**Азамат.** Бер килеш, мөхтәрәм ага! Ниятем – изге.

**Аман.** Илебезгә рәхим ит, алайса. Андый кунакларга капкаларыбыз да, күңелебез дә ачык! Эше барның ашы бар. Эшли-эшли сөйләшик. Син шактый дөнья күргәнгә охшыйсың. Акыл төбе – тәҗрибә, ди безнең халык. Бер-ике хикмәтле сүз әйтсәм, җавабын табарсыңмы?

**Азамат.** Белгәннән белмәгәнем күп, күргәннән күрмәгәнем күп. Алай да, әйтеп карагыз.

*Аман берет зерна в пригорошню и рассыпает первую горсть.*

**Аман.** Менә бер тапкыр чәчтем. Бусы – бурычымны түләргә булды.

*Бросает вторую горсть.*

**Аман.** Икенче тапкыр чәчтем. Бусы – бурычка биреп торуым.

*Бросает третью горсть.*

**Аман.** Өченче тапкыр чәчтем. Бусы – йортымның бәхете хакына. Төшендеңме?

## 4 картина (≈ 3 мин.)

*Начинается подготовка к соревновательной части Сабантуя,которая запланирована на следующий день: выносится инвентарь,тренируются джигиты,наряжаются жеребцы и пр.*

**Азамат** *(обращает внимание на суету)*. Иртәгә берәр бәйрәмме әллә?

**Аман.** Нинди генә бәйрәм әле – Сабан туе! Йоласын башкардык инде. Ярышлары иртәгә узачак. Иртәгә бердәнбер, сөекле кызым Нажар Сабан туе батырына ярәшәчәк!

**Азамат** *(растерянно)*. Нажар? Нажар, дисезме?..

**Аман.** Әйе, Аман би кызы Нажар!

*Азамат судорожно садится верхом на коня,спешно уезжает.*

**Аман** *(вслед за ним)*. Ут каптымы әллә, кая чабасың? Табышмакларны соң!.. Җавап бирмәдең бит!.. *(Машет рукой.)* Йә, исән йөр, алайса.

*Кам выходит на середину майдана.*

**Кам.** Батыр туса – ил бәхете, яңгыр яуса – җир бәхете. Сабан туйларыннан соң шифалы яңгыр явып үтсә, игеннәр мул булыр, илгә байлык-бәхет килер! Ул очракта Табигать безнең теләкләрне кабул итәр, безне үзенең бер өлеше итеп таныр!

*Уходит.*

**ГЗК.** Мин быелгы ярышларга җаным-тәнем белән каршы. Батырга бүләк булыр өчен тәкә түгел лә мин! Минем сөйгән ярым бар. Исеме җисеменә туры килердәй – Азамат. Ул күрше катаудан. Өч ел элек, кәрваннарның берсенә ияреп, Шәһри Биләргә юл тотты. Анда бер акыл иясе Гыйлем йорты ачкан, имеш. Уку кешене күзле итә дип Азаматым җыенып китте дә... Бүтән күренмәде. Әле дә ярый хәлемне аңларга, серемне бүлешергә кошлар бар.

*Начинается танец «птиц». К Аману выбегает Наджар.*

**Наджар.** Харап итмә, атам! Зинһар, Сабан туе – Сабан туе булып калсын. Ике йоланы бутама!

**Аман.** Кыз язмышы – кош язмышы. Вакыт җиткәч, очып китәргә кирәк.

Наджар. Атам, зинһар, дим! Һичьюгы, ярышларны тагын бер елга күчер. Кеше күңеле – пыяла. Җанымны ватма, ал сүзеңне!

**Аман.** Әйткән сүз – аткан ук. Тәмам. Мин әйттем!

*Наджар в плаче убегает.*

**Аман.** Елый. Еласын. Кияүгә елап чыккан кыз кияүдә көлеп яшәр.

## 5 картина (≈ 5 мин.)

*Утро следующего дня. Бьют барабаны. Трубят трубы. Аман и Кам встречают участников соревнований. Джигиты строятся в ряд. К ним подходит Азамат.*

**Аман.** Син нишләп йөрисең монда?

**Азамат.** Ярышырга җыенам.

**Аман.** Син – чит нәсел-ыру кешесе. Бар, юлыңда бул.

**Кам** *(Аману)*. Батыр – ил башлыгы кебек үк – Күкләр тарафыннан сайланып, Җиргә иңдерелгән зат. Җиңелсә – җиңелер, җиңсә... Тәңренең язганы шул, димәк! Тәңрегә каршы барырга җыенмыйсыңдыр бит?

**Аман.** Яхшы, Кам баба. Синеңчә булсын.

*Начинаются соревнования. Кам выполняет роль судьи.*

*Первое состязание – стрельба из лука.*

**ГЗК.** Егет мәйданда беленә. Бездә бу ярышлар – гадәти ярышлар гына түгел. Һәрберсенең нигезендә – тирән мәгънә ята: җәядән ук очыру – язгы кояшны, тәүге сабан нурларын белдерә.

*Второе состязание – перетягивание каната и бой мешками.*

**ГЗК.** Аркан тартышу – өске һәм аскы дөньяларның көч сынашуы, дип сөйли өлкәннәр. Бу ярышларның барысы да ир-егетләрне көчле, тапкыр, җитез итеп үстерүгә юнәлтелгән. Капчык белән сугышу – нинди генә сынау килсә дә, биләгән урыныңнан егылып төшмәскә, егылып төшсәң, яңадан үз урыныңны яулап алырга өйрәтә.

*Третье состязание – лазание по наклонному шесту.*

**ГЗК.** Авыш баганага менү – нинди хәлгә тарысаң да, югалып ка́лмаска, максатыңа таба барырга һәм аңа ирешергә өйрәтә.

*Четвертое состязание – национальная борьба.*

**ГЗК.** Көрәш – иң олы, иң мәртәбәле ярыш. Билгә уратылган кушак – Кешене Галәм белән тоташтырып торган кендек бавын белдерә. Көрәш батыры, ил башлыгы сыман, Җиргә Күкләр тарафыннан иңдерелгән зат булып санала.

*Азамат выигрывает все соревнования. Ему,как батыру,на плечи кладут барана.*

*Он проходит с ним круг почета.*

**ГЗК.** Тәкә – кояшның җирдәге сыңары. Батыр калган егет, тәкәне иңенә салып, мәйдан әйләнергә тиеш. Бу – аның, кояшны иңнәренә салып, дөнья тирәли әйләнергә сәләтле булуын аңлата.

*Все ликуют. Бросают Азамата в небо.*

**ГЗК.** Кеше күңеле – кара урман. Бу вакытта мин бертуган Тимербулат абыемның җанында нинди давыллар котырганын белми идем.

*На середину майдана выходит Тимербулат – брат Наджар.*

**Тимербулат.** Мин каршы! *(Тишина.)* Шоңкар юкта ябалак мәйдан тотар. Тимербулат абыйсы янында сеңелемә берни куркыныч түгел иде! Аңа усал караш ташлаучы да булмады. Нажар сеңелемә дәгъва белдерүче зат минем белән ярышып карасын! «Аударыш»та́ сынашыйк!

**ГЗК.** «Аударыш» уенында Тимербулат абыйга тиңнәр юк иде. Билгесез якларда үскән, безнең йолаларны белмәгән, ат җанын тоймаган ир-егет бу ярышта һичничек җиңә алмас кебек иде...

*Пятое состязание – «аударыш».*

*Азамат побеждает. Его возносят к небу.*

**ГЗК.** Ләкин ул җиңде. Без ил белән аһ иттек.

## *6 картина* (≈ 3 мин.)

**ГЗК.** Үлемнән хурлык яман. Мин хурланудан үземә урын тапмадым...

*Наджар выходит на майдан,к Азамату.*

**Наджар.** Минем дә бер шартым бар! Соңгысы – Тәңре шаһит. (Тынлык.) «Кыз куу»! (Азамату.) Атның даны егет кулында. Атыңны хур итмәссең бит? «Кыз куу» – халкыбызның борынгы уены. Ир-егет ат өстендә чабып барган көе кыз-кыркынны үбеп алырга тиеш. Җитезлеге җитмичә, ир-егет җиңелсә, кыз-кыркын аны камчы белән кыйнарга ирекле...

*Шестое состязание – «кыз куу» («погоня за девушкой»).*
*Азамат проигрывает.*

## *7 картина* (≈ 1 мин.)

*Наджар спешивается,три раза ударяет камчой юношу. Один удар приходится на чалму. Чалма падает,обнажая голову и лицо Азамата.*

**Наджар** *(узнает его)*. Азамат?!. Син?!.

**Народ:** «Азамат? Азамат... Азамат!»

**Наджар.** Мин сине өч ел буе «бүген кайтыр!» диеп көттем...
**Азамат.** Кичер, Нажар! Тәкъдирем шулай йөртте. Юл ахыры – юл башы икән. Ярты дөньяны кичтем дисәм, киметү булыр, бәлки. Әмма арттыру булмас. Һәркайда белем тупладым мин, һөнәрләр үзләштердем. Кайсы илләр – фарфор ясарга, тукыма тукырга, пыяла эшкәртергә, кайсы илләр – ташчылыкка, зәркәнчелеккә өйрәтте. Дөнья зур икән, Нажар! Кунак ашы – кара-каршы, диләр. Мин булган җирләрдә яшәүчеләр бер җыелып безгә дә килер әле. Капкаларыбыз алар өчен ачык булыр! Тәрәзәләребездән бөтен дөнья күренер! *(Достает и дарит Наджар хаситэ)*. Шушы бүләгемне сәфәрем истәлеге һәм... мәхәббәтем билгесе буларак кабул ит.
*Хореографический номер с детьми.*

## *8 картина* (≈ 4 мин.)

*К Наджар с Азаматом подходят Аман с женой,Отец и Мать Амана,Тимербулат и др.*

**Аман.** Мин сине беренче күрүдә үк таныдым, Азамат. Шуңа күрә ярышларга кертергә теләмәдем дә. Үҗәт булып чыктың! Максатыңа ирешә беләсең икән! Белэгең нык, ә белемең сынатты менә. Без очрашкач та мин өч тапкыр ашлык чәчтем, хәтерлисеңме? Беренчесендә: «Бусы – бурычымны түләргә булыр», – дидем. Сүзем ни турында иде?

**Азамат** *(подумав)*. Сезнең яндагы мөхтәрәм картлар – ата-анагыз бит?

**Аман.** Нәкъ үзләре. Ата-ана – алтын канат.

**Азамат.** Үз вакытында алар сезне тәрбияләгән, ашаткан-эчерткән. Хәзер инде сез аларны тәрбияләргә, шулай итеп бурычыгызны кайтарырга тиеш.

**Аман.** Дөрес. Икенчесендә: «Бусы – бурычка биреп торуым», – дидем.

**Азамат.** Сезнең күз явын алырлык Нажар кызыгыз һәм чын баһадир – Тимербулат улыгыз бар. Бүген, ата-ана буларак, сез аларга тәрбия бирәсез. Алар сезгә бурычлы булып кала.

**Аман.** Янә дөрес әйттең. Өченче тапкыр чәчкәндә: «Бусы – илемнең бәхете хакына», – дигән идем...

**Азамат.** Без – бик кунакчыл халык. Бездә: «Кунак бәхете белән килә», «Кунак килсә кот килә», – диләр. Димәк, өченче уч ашлык – кадерле кунаклар хөрмәтенә чәчелә!

**Аман.** Кеше күрке – акыл! Һәр яктан камил егет икәнсең. Афәрин! Бездән сезгә хәер-фатиха!

*Начинается веселье. Играют музыкальные инструменты. Вдруг начинает лить дождь.*

**Кам.** Күрегез, яңгыр ява түгелме соң? Сабан яңгыры ява бит! Бәхет ява, күрегезче! Җир-Анабызга төшкән орлыклар Күкнең «Амин!» дигән сәгатенә туры килгән! Табигать безне үзенең бер өлеше итеп таныды, теләкләребезне кабул итте! Шөкер! Шөкер!

## *9 картина* (≈ 3 мин.)

*Переход к осени и свадьбе.*

**ГЗК.** Ул елны, чыннан да, уңыш ишеп унды. Барлык тирмәләр, базлар иген белән шыплап тулды. Сабан төбе – сары алтын шул.

Көз җиткәч, тирә-юньгә дан итеп, шау-гөр килеп туйлар узды.

Ныклы гаилә – ныклы дәүләт, дигән сүз. Без, бер илдә яшәүчеләр, барча халыклар – зур, тату гаилә. Дәүләтебезнең даны бөтен кыйтгаларга таралсын! Тәрәзәләребездән бөтен дөнья күренеп торсын! Аклык, дуслык, намус билгесе булган Сабан туе сөлгесе аяз күктә мәңге җилфердәсен!

Изге ният белән килгән һәр кунакка безнең капкалар да, күңелләребез дә ачык! Ипи-тоз – якты йөз!

